БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«03» 09 2021 ел № 277

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында СПИДка, туберкулезга, ВИЧ-инфекциясенә каршы көрәш буенча ведомствоара комиссия нигезләмәсен һәм аның составын раслау турында

«Халыкның санитар-эпидемиология иминлеге турында» 1999 елның 3 декабрендәге 52-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә туберкулезның таралуын кисәтү турында» 2001 елның 18 июнендәге 77-ФЗ номерлы, «Кеше иммунодефициты вирусы (ВИЧ-инфекция) китереп чыгара торган авыруларның Россия Федерациясендә таралуын кисәтү турында» 1995 елның 30 мартыннан 38-ФЗ номерлы федераль законнарны үтәү йөзеннән, муниципаль районда яшәүчеләр арасында СПИД, туберкулез, ВИЧ-инфекция, башка социаль әһәмияткә ия авыруларны профилактикалау, иртә ачыклау һәм киметү буенча кичектергесез чаралар күрү максатларында, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Расларга:

1.1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында СПИДка, туберкулезга, ВИЧ-инфекциясенә каршы көрәш буенча ведомствоара комиссия нигезләмәсен (1 нче кушымта);

1.2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында СПИДка, туберкулезга, ВИЧ-инфекциясенә каршы көрәш буенча ведомствоара комиссия составын (2 нче кушымта);

2. Әлеге карарны Интернет-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче А.Ф. Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2021 елның 03.09
277 номерлы карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында СПИДка, туберкулезга, ВИЧ-инфекциясенә каршы көрәш буенча ведомствоара комиссия нигезләмәсе

1. СПИДка, туберкулезга, ВИЧ-инфекциягә каршы көрәш буенча ведомствоара комиссия (алга таба - комиссия) СПИД, туберкулез, ВИЧ-инфекция эпидемиясе таралуын кисәтү, Балтач муниципаль районы территориясендә СПИД, туберкулез, ВИЧ-инфекция авыруларын профилактикалауга, кисәтүгә һәм санитар-эпидемиологик иминлекне тәэмин итүгә юнәлтелгән мәсьәләләрне хәл итү чараларын планлаштыру буенча ведомствоара хезмәттәшлекне координацияләү өчен булдырылган даими киңәшмә орган булып тора.

2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының гамәлдәге законнарына, муниципаль хокукый актларга, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

3. Комиссиянең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

бердәм стратегияне формалаштыру һәм СПИД, туберкулез, ВИЧ-инфекция белән массакүләм авыруларны профилактикалау һәм халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру чараларын эшләүдә катнашу;

СПИДны, туберкулезны, ВИЧ-инфекцияне профилактикалау буенча төп социаль, медицина, икътисадый һәм башка проблемаларны комплекслы өйрәнү;

СПИДка, туберкулезга, ВИЧ-инфекциягә каршы көрәш, халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итү буенча максатчан программаларны эшләүдә катнашу;

Россия Федерациясенең санитар законнарын бозу нәтиҗәсендә гражданнарның сәламәтлегенә китерелгән зыянны каплау мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр эшләүдә катнашу.

4. Комиссия үзенә йөкләнгән бурычлар нигезендә түбәндәге функцияләрне башкара:

- «Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә халыкның санитар-эпидемиологик имин булмавы барлыкка килүгә бәйле мәсьәләләрне оператив хәл итүне оештыру;

- «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә санитар-эпидемиологик хәлнең торышын анализлау, аның үзгәрешләре һәм Россия Федерациясенең санитар законнарын үтәү буенча тәкъдимнәр;

- халыкка массакүләм мәгълүмат чаралары аша комиссия эшчәнлегенең юнәлешләре һәм нәтиҗәләре турында мәгълүмат бирү.

5. Комиссия хокуклы:

- СПИДның, туберкулезның, ВИЧ-инфекциянең таралуын кисәтү буенча чараларны тормышка ашыру буенча кайсы ведомсвога каравына, оештыру-хокукый формасына карамастан предприятие, оешма, учреждение җитәкчеләреннән кирәкле материалларны соратып алырга;

- үз утырышларында җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затларын, предприятие, учреждение һәм оешма җитәкчеләрен, аларның нинди ведомствога каравына һәм оештыру-хокукый формасына карамастан, СПИД, туберкулез, ВИЧ-инфекция авыруларын профилактикалауга һәм халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру турында тыңларга;

- җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затларына, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар җитәкчеләренә СПИД, туберкулез, ВИЧ-инфекция белән чирләүнең торышы, аларның үзгәрешләрен фаразлау, профилактика чаралары, аларга каршы көрәш чаралары комплексы турында мәгълүмат бирү;

- СПИД, туберкулез белән авыру очракларына юл куелган яки ВИЧ - инфекцияне таратуда гаепле вазыйфаи затларны һәм гражданнарны җаваплылыкка тарту мәсьәләсен хәл итү өчен тиешле органнарга мәгълүмат бирергә.

6. Комиссиянең эш тәртибе.

6.1. Комиссия вәкиллекле нигездә формалаша. Комиссия составына җирле үзидарә органнары вәкилләре, шулай ук килешү буенча башка органнар һәм оешмалар, иҗтимагый берләшмәләр вәкилләре, галимнәр, белгечләр һәм җәмәгать эшлеклеләре кертелә. Комиссия әгъзалары үз эшчәнлекләрен иҗтимагый башлангычларда алып баралар һәм аның утырышларында шәхсән катнашалар. Комиссия утырышларына прокуратура, суд, эшкуарлык структуралары, иҗтимагый оешмалар вәкилләре чакырылырга мөмкин. Комиссия утырышлары кварталга кимендә 1 тапкыр үткәрелә.

6.2. Комиссия үз эшчәнлеген комиссия рәисе раслаган эш планы нигезендә башкара. Комиссия утырышын комиссия рәисе, ул булмаганда - комиссия рәисе урынбасары үткәрә.

6.3. Комиссия составының яртысыннан артыгы катнашса, комиссия утырышы тулы хокуклы була. Комиссиянең барлык карарлары комиссия әгъзаларының гомуми составының күпчелек тавышы белән кабул ителә.

6.4. Комиссия карарлары утырышта рәислек итүче тарафыннан раслана һәм комиссия секретаре тарафыннан имзалана торган утырыш беркетмәләре рәвешендә рәсмиләштерелә. Карарлар кызыксынган предприятие, учреждение, оешмалар җитәкчеләре, аларның нинди ведомствога каравына һәм оештыру-хокукый формасына карамастан, вазыйфаи затлар һәм гражданнар игътибарына тиешле өземтә рәвешендә җиткерелә. Комиссия карарлары тәкъдим итү характерына ия.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2021 елның 03. 09
227 номерлы карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында
СПИДка, туберкулезга, ВИЧ-инфекциясенә каршы көрәш буенча
ведомствоара комиссия составы

| | |
|---|---|
| Гәйнетдинов И. Ф. | Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, комиссия рәисе |
| Шайхутдинова З.Г. | Балигъ булмаганнарың эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия белгече, комиссия секретаре |
| **Комиссия әгъзалары** | |
| Шагаева А. Ю. | «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы |
| Петров И.И. | Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының мәдәният бүлеге башлыгы |
| Заһидуллин Р. Р. | Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге башлыгы |
| Дәүлиев Г. Д. | «Балтач РҮХ» ДАССУнең баш табибы (килешү буенча) |
| Усманов И. К. | Россия Эчке эшләр министрлыгының Балтач районы буенча бүлеге начальнигы (килешү буенча) |
| Зәкиев В. М. | «Хезмәт» район газетасы баш мөхәррире (килешү буенча) |